**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«06» 12 2021 ел Яр Чаллы № 4355

2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасын раслау турында

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы ( 2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы, 2005 елның 11 октябрендәге 101-ТРЗ номерлы, 2009 елның 3 февралендәге 9-ТРЗ номерлы, 2009 елның 29 июлендәге 61-ТРЗ номерлы, 2009 елның 4 декабрендәге 61-ТРЗ номерлы, 2011 елның 15 мартындагы 3-ТРЗ номерлы, 2012 елның 17 маендагы 25-ТРЗ номерлы, 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы, 2014 елның 23 июлендәге 60-ТРЗ номерлы, 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы, 2021 елның 05 мартындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә) Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы»н кушымта нигезендә расларга.
2. Оешма, учреждение, предприятие җитәкчеләренә, милек формаларына бәйсез рәвештә, әлеге программаны тормышка ашыру буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә.
3. Хезмәтне саклау буенча координацион советка предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә хезмәтне саклау торышын контрольдә тотуны тәэмин итү буенча максатчан эш алып барырга, аларга кирәкле методик ярдәм күрсәтергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм район сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Н. Яббаров

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1639031830

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетның 2021 елның 06.12 1335 номерлы карарына кушымта

# 2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы

**Яр Чаллы шәһәре, 2021**

**ЭЧТӘЛЕГЕ**

| № | **Бүлекләр исеме** |
|---|---|
| | «2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы» паспорты |
| 1. | Программаның максатлары, бурычлары, чаралары һәм нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары |
| 2. | Программа чаралары системасы |

**«2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы» паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законы (2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы, 2005 елның 11 октябрендәге 101-ТРЗ номерлы, 2009 елның 3 февралендәге 9-ТРЗ номерлы, 2009 елның 29 июлендәге 61-ТРЗ номерлы, 2009 елның 4 декабрендәге 61-ТРЗ номерлы, 2011 елның 15 мартындагы 3-ТРЗ номерлы, 2012 елның 17 маендагы 25-ТРЗ номерлы, 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы, 2014 елның 23 июлендәге 60-ТРЗ номерлы, 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы, 2021 елның 05 мартындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары редакциясендә) |
| Программаны төп эшләүчеләр | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның координаторы һәм башкаручылары | Координатор – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>Башкаручылар – район предприятиеләре, учреждениеләре, оешмалары (килешү буенча) |
| Программаның максаты: | Хезмәтне саклауга һәм хезмәт шартларына куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган конституция гарантияләрен тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | Эш бирүче тарафыннан сәламәт һәм имин хезмәт шартлары булдыруны тәэмин итүче һәм стимуллаштыручы икътисадый һәм оештыру принципларын формалаштыру;<br>Хезмәтне саклау дәүләт идарәсе системасын үстерү;<br>Производствода имгәнүләр, һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү;<br>Район оешмаларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау торышын яхшырту |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2022-2024 еллар |
| Финанслау чыганаклары Программаны | Программаны финанслауның гомуми күләме 398 356 702,3 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- район предприятиеләре хисабына<br>2022 ел - 126 006 242,9 сум<br>2023 ел - 132 665 297,2 сум<br>2024 ел - 139 685 162,2 сум |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре, нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 1. Социаль нәтиҗә:<br>- начар хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын киметү; |

| | |
|---|---|
| | - производствода имгәнүләр, һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү;<br>- хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч производство факторларыннан саклау дәрәҗәсен күтәрү;<br>- хезмәткәрләргә имин хезмәт шартларын тәэмин итүгә конституция хокукын гамәлгә ашыру.<br>2. Икътисадый нәтиҗә:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан, производство белән бәйле авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнар киму;<br>- производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплау чыгымнар киму;<br>- зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында, авыр хезмәт шартларында эшләгән өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнар киму;<br>- производствода имгәнү яки һөнәри авыру аркасында инвалидлык дәрәҗәсе киму |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаның үтәлешен контрольдә тоту гамәлгә ашырыла:<br>Тукай муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координацион советы |

**2022-2024 елларга Тукай муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасының максатлары, бурычлары, чаралары һәм нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары**

| Максат исеме | Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре |
|---|---|---|---|---|
| Хезмәтне саклауга һәм хезмәт шартларына куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирә торган конституция гарантияләрен тәэмин итү | 1. Эш бирүче тарафыннан сәламәт һәм имин хезмәт шартлары булдыруны тәэмин итүче һәм стимуллаштыручы икътисадый һәм оештыру принципларын формалаштыру | 1.1. | Барлык оештыру-хокукый һәм милек формасындагы оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча иң яхшы оештырылган эш район смотр-конкурсын үткәрү | Киметү:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын 1000 эшләүчегә исәпләгәндә - 1000 эшләүчегә 0,2 кешегә кадәр;<br>- санитар-гигиена нормаларына туры килми торган хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын - 26,0% ка кадәр;<br>- производство имгәнүләре һәм травмалары аркасында бер зыян күргән кешегә исәпләгәндә эшкә яраксызлык көннәре санын - 4,00 кеше-көнгә кадәр |
| | | 1.2. | Милек формаларына бәйсез рәвештә оешма, учреждение, предприятие җитәкчеләренә хезмәтне саклау буенча укулар узарга тәкъдим итәргә | |
| | | 1.3. | Массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау (хезмәтне саклау буенча оператив мәгълүмат, норматив документлар бастырып чыгару һ.б.) | |
| | 2. Хезмәтне саклау дәүләт идарәсе системасын үстерү | 2.1. | Хезмәтне саклау буенча яңа законнарны, нигезләмәләрне, норматив-техник документларны өйрәнү буенча, район предприятиеләрендә травматизмны һәм хезмәтне саклау торышын анализлап, семинарлар үткәрү | Киметү:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын 1000 эшләүчегә исәпләгәндә - 1000 эшләүчегә 0,2 кешегә кадәр.<br>- санитар-гигиена нормаларына туры килми торган хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын - 26,0% ка кадәр;<br>- производство имгәнүләре һәм травмалары аркасында бер зыян күргән кешегә исәпләгәндә эшкә яраксызлык көннәре санын - 4,00 кеше-көнгә кадәр |
| | | 2.2. | Район предприятиеләре, учреждениеләре, оешмаларын производство травматизмы торышы турында мәгълүмат белән тәэмин итү | |
| | | 2.3 | Елга бер тапкыр район күләмендә Хезмәтне саклау көне үткәрү, мондый чараларны предприятиеләрдә үткәрүне тәкъдим итәргә | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 3. Район оешмаларында производство травматизмы, һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү, хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау торышын яхшырту | 3.1. | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә, спорт учреждениеләрендә, авыл җирлекләрендә хезмәт шартларын һәм имгәнүләр куркынычсызлыгын махсус бәяләү уздыру | Киметү:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын 1000 эшләүчегә исәпләгәндә - 1000 эшләүчегә 0,2 кешегә кадәр;<br>- санитар-гигиена нормаларына туры килми торган хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын - 26,0% ка кадәр;<br>- производство имгәнүләре һәм травмалары аркасында бер зыян күргән кешегә исәпләгәндә эшкә яраксызлык көннәре санын - 4,00 кеше-көнгә кадәр |
| | | 3.2. | Районның барлык предприятиеләрендә эшләүчеләрне шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү һәм аларны дөрес куллану | |
| | | 3.3. | Районның барлык предприятиеләрендә янгын сүндерү чаралары булуын һәм аларның төзеклеген тәэмин итү | |
| | | 3.4. | Районның барлык предприятиеләрендә вентиляция системаларының, җирле отсосларның, тузан тоткыч җайланмаларның, саклагыч һәм сигнализация җайланмаларының, контроль-үлчәү приборларының төзеклеген һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итү | |
| | | 3.5. | Районның барлык предприятиеләрендә зарарлы һәм янгын куркынычы булган матдәләр һәм материаллар белән эшләгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итү, чимал, ярымфабрикатлар һәм әзер продукция туплау кагыйдәләрен үтәү | Киметү:<br>- производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән кешеләр санын 1000 эшләүчегә исәпләгәндә - 1000 эшләүчегә 2,3 кешегә кадәр;<br>- санитар-гигиена нормаларына туры килми торган хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын - 14.55% ка кадәр;<br>- авыр физик хезмәт башкаручы хезмәткәрләрнең чагыштырма зурлыгын - 1,05% ка кадәр |
| | | 3.6. | Электр җайланмаларында һәм электр инструментлары белән эшләгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итү, ел саен электр җайланмаларын җир белән тоташтыру системаларын тикшерү һәм үткәргечләрнең изоляция каршылыгын тикшерү | |
| | | 3.7. | Технологик, йөк күтәрү, транспорт, энергетика һәм башка җиһазларның хезмәт куркынычсызлыгы стандартлары һәм хезмәтне саклау буенча башка норматив-техник документлар таләпләренә туры килүен тәэмин итү | |
| | | 3.8. | Эшләүчеләргә медицина тикшерүләрен үткәрүне тәэмин итү | |

## Программа чаралары системасы

| | Программа чаралары исеме | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме, барлыгы, сумнарда | Шул исәптән сроклар буенча, сумнарда | | | Программа чараларын башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 | 2023 | 2024 | |
| 1. | Барлык оештыру-хокукый һәм милек формасындагы оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча иң яхшы оештырылган эш район смотр-конкурсын үткәрү | | Финанслау таләп итми | | | | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Тукай муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча) |
| 2. | Барлык оештыру-хокукый формадагы һәм милек формаларындагы оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре өчен хезмәтне саклау буенча укулар | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 3 397 805,6 | 1 103 549,7 | 1 177 850,2 | 1 116 405,7 | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре (килешү буенча) |
| 3. | Массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау (хезмәтне саклау буенча оператив мәгълүмат, норматив документлар бастырып чыгару һ.б.) | | Финанслау таләп итми | | | | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 4. | Хезмәтне саклау буенча яңа законнарны, нигезләмәләрне, норматив-техник документларны өйрәнү буенча, район предприятиеләрендә травматизмны һәм хезмәтне саклау торышын анализлап, семинарлар үткәрү | | Финанслау таләп итми | | | | «Яр Чаллы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ Тукай муниципаль районы буенча филиалы (килешү буенча) |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Район предприятиеләре, учреждениеләре, оешмаларын производство травматизмы торышы турында мәгълүмат белән тәэмин итү | | Финанслау таләп итми | | | | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 6. | Район күләмендә Хезмәтне саклау көнен үткәрү, предприятиеләрдә шундый чаралар үткәрүне кварталга 1 тапкыр тәкъдим итәргә | | Финанслау таләп итми | | | | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Тукай муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча) |
| 7. | Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә, спорт учреждениеләрендә, авыл җирлекләрендә хезмәт шартларын һәм имгәнүләр куркынычсызлыгын махсус бәяләү уздыру | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 1 158 150 | 263 000 | 599 000 | 296 150 | Районның авыл хуҗалыгы предприятиеләре (Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән килешү буенча), учреждениеләр җитәкчеләре |
| 8. | Районның барлык предприятиеләрендә эшләүчеләрне шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү һәм аларны дөрес куллану | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 108 567 475 | 34 139 319 | 36 106 710 | 38 321 446 | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре (килешү буенча) |
| 9. | Районның барлык предприятиеләрендә янгын сүндерү чаралары булуын һәм аларның төзеклеген тәэмин итү | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 3 823 573,74 | 1 192 916,24 | 1 261 950 | 1 368 707,5 | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре (килешү буенча) |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | Районның барлык предприятиеләрендә вентиляция системаларының, җирле отсосларның, тузан тоткыч җайланмаларның, саклагыч һәм сигнализация җайланмаларының, контроль-үлчәү приборларының төзеклеген һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итү | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 11 877 472 | 5 110 981 | 3 281 959 | 3 484 532 | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре (килешү буенча) |
| 11. | Районның барлык предприятиеләрендә зарарлы һәм янгын куркынычы булган матдәләр һәм материаллар белән эшләгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итү, чимал, ярымфабрикатлар һәм әзер продукция туплау кагыйдәләрен үтәү | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 29 011 200 | 8 281 600 | 9 725 400 | 11 004 200 | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре (килешү буенча) |
| 12. | Электр җайланмаларында һәм электр инструментлары белән эшләгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итү, ел саен электр җайланмаларын җир белән тоташтыру системаларын тикшерү һәм үткәргечләрнең изоляция каршылыгын тикшерү | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 2 965 500 | 952 800 | 1 036 700 | 976 000 | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре (килешү буенча) |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Технологик, йөк күтәрү, транспорт, энергетика һәм башка җиһазларның хезмәт куркынычсызлыгы стандартлары һәм хезмәтне саклау буенча башка норматив-техник документлар таләпләренә туры килүен тәэмин итү | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 174 621 460 | 5 219 300 | 58 491 410 | 60 910 750 | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре (килешү буенча) |
| 14. | Районның барлык предприятиеләрендә эшләүчеләргә даими медицина тикшерүләре үткәрүне тәэмин итү | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре средстволары | 55 913 340 | 17 513 160 | 18 648 533 | 18 751 647 | Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре; «Тукай районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча) |